ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«11» гыйнвар 2024 ел №3

**«Торакны торак бина, торакны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында» 2020 елның 18 декабрендәге 1035 номерлы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Торакны торак бина, торакны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмә» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Торакны торак бина, торакны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында» 2020 елның 18 декабрендәге 1035 номерлы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Торакны торак бина, торакны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе составын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.01.2024 ел, № 3
карарына кушымта

**Торакны торак бина, торакны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р. М. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Галимуллин И.Ә. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Хәсәнов И.М. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы, комиссия секретаре. |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Касыймов Р.Ф. | - Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Әгълиев И.К. | - «Арча муниципаль районының идарәче компаниясе» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Гатиятова Е.Н. | - «Татарстан Республикасының техник инвентаризация бюросы» АҖ бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Арефьева Е.Н. | - Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Салкова Э.В. | - Арча, Биектау, Әтнә, Балтач районнары буенча баш дәүләт санитар табибы (килешү буенча). |

Искәрмә: Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл иткәндә комиссия составына торак урнашкан территориядәге авыл җирлекләре башлыклары кертелә.